**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлегенең Нарат - Асты авылы торак пунктында
2023 елда үзара салым кертү турында

**2022 ел, 23 ноябрь** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Нарат - Асты авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Нарат - Асты авылы территориясендә I төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Нарат-Асты торак пунктында урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы лампалар сатып алу һәм урнаштыру) ;

2) Нарат - Асты авылында (Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Инвалидлар, юбилярлар көне) чаралар уздыру өчен азык-төлек җыелмалары сатып алу;

3. Җыен нэтижэлэрен Чукмарлы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтынд(https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы: И.Х.Хадиуллин